

Салават күпере



Төркиягә сәяхәт

Күп кенә кешеләрнең ял итәргә Төркия дигән илгә барып кайтуларын беләбез инде. Нинди ил соң ул Төркия? Ял итәргә, кояш нурларында кызынырга һәм диңгездә коенырга күп кеше шул илгә бару турында хыяллана. Әллә оҗмахның үзе микән анда?

Ошбу сорауларга җавап табу өчен без бу санда Төркиягә сәяхәт итәчәкбез.

Рәхим ит, балакаем, Төркиягә. Аңламаган мәсьәләләр, сораулар булса, сиңа өлкәннәр ярдәм итәр.



Төркия – ярымутрау.

Төркиянең өч ягы диңгезләр белән уратылып алынган. Ак диңгез (Урта диңгез), Мәрмәрә (Мәрмәр) диңгезе, Әгәй диңгезе.

Күрше илләре: Греция, Болгария, Грузия, Әрмәнстан, Әзәрбайҗан, Иран, Гыйрак һәм Сүрия.



Истиклял (бәйсезлек) маршы – Төркиянең Дәүләт гимны.

Аның сүзләрен 1922 елда Мәхмәт Акиф ИРСОЙ,
көен 1924 елда Госман Зәки ҮНГҮР язган.

Курыкма, төшмәс бу шәфәкъләрдә йөзгән ал байрак;
Сүнмәс йортыбыз өстендә төтенләп соң учак.
Ул минем милләтем йолдызыдыр – яначак;
Ул – минеке, ул минем милләтемдер һәрчак.
Ятма, корбан булмас ул һичкайчан назлы һилал!*
Каһарман ыруыма гөл! Син көчле дә, син гүзәл.
Синең өчен түгелгән каннарыбыз булыр хәләл,
Хакка табынсак, килер халкыбызга истиклял.
Без һәрвакыт дөньяда хөр яшәдек, хөр яшәрбез.
Нинди тинтәк безгә зынҗир кидермәкче? Шашарбыз;
Күкрәрбез сил шикелле, һәм күкләргә ашарбыз,
Тауларны ертып, офыкларга сыймый ташарбыз.
Көнбатыш явын кире кагар корыч көбәле дивар,
Күкрәгебез тулы иман – безнең яклаучыбыз бар.
Олы син, курыкма! Сиңа өстән кодрәтле тәңре багар,
«Мәдәният!» диеп кенә тешсез калырмы җанвар?
Аркадаш! Йортка түбәнлек килүеннән син саклан!
Гәүдәң белән капла, туктар безгә каршы агым.
Туачактыр безгә вәгъдә ителгән көне хакның;
Туар бәлки иртәгә ул, бәлки аннан да якын.
Баскан җиреңне «туфрак» диеп үтмә һич тә, син таны –
Төшен, аяк астында күпме кәфенсезнең ятагы.
Син – шәһидләрнең улы, языктыр оныту атаны;
Бирмә дөнья нигъмәтенә бу җәннәтле ватанны.
Кем бу җәннәт ватаны өчен җанын итмәс фида?
Шәһид булып ашла туфракны, мәңгелек дан шәһидкә!
Ил хакына бөтен барлыгымны алсын да Хода,
Тик ватаннан аермасын, аермасын ул һич тә.
Рухым синдә, и Илаһым, шулдыр минем теләгем –
Кагылмасын изге җиргә дошманнарымның кулы.
Бу азаннар шәһадәтнең асыл дәлиле булып
Яңгырасын ил өстендә, авазы якты, олы.
Ул заман сәҗдә итәр, әгәр булса, кабер ташым;
Һәрбер ярамнан, Илаһи, түгелер канлы яшем.
Җәсәдне калдырып җирдә калкыр да өскә җаным,
Ул заман бәлки күкләргә кагылыр минем башым.
Ялкынлан син дә шәфәкъләр кебек, и шанлы һилал!
Булсын түгелгән каннарыбызның һәммәсе хәләл.
Юкса һичбер кайчан килмәс халкыма минем ирек.
Хактыр, хөр яшәрбез һаман байракны өстә тотып,
Хактыр, Хакка табынган милләтемә - истиклял!

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе.



Төркия гербы


Төркия флагы

*һилал – яңа туган ай.



Диңгезле һәм җылы кояшлы булганы өчен генә Төркиягә барырга булдыкмы соң без? Юк, юк, әлбәттә. Төркиядә яшәүче төрек халыклары – без татарларның туганнары, кан кардәшләре. Без үз туганнарыбызга кунакка барабыз. Ни дисәң дә, ата-бабаларыбыз бер бит. Без барыбыз да – төркиләр.

Димәк, киттек кунакка!..

Анкара

Анкара – Төркиянең баш шәһәре. Анда 7 миллион кеше яши.

Анкара Ауропа шәһәрен хәтерләтә. Шәһәрне шул рәвешле алман архитекторы Янсен планлаштыра. Урамнары төз, яшеллеккә бай. Унсигез катлы кунакханәләр, чат саен кибет. Президент сарае да шушында урнашкан.

Анкара – илнең иң уңышлы кешеләре яши торган шәһәр. Аның университеты бөтен дөньяда дан тота!

Урам тулы кибет, каһвәханә, ресторан – һәммәсендә халык кайнаша. Тауарларын тротуарга тезеп куйган кырыктартмачылар бихисап.

Анкараның дәүләт башкаласы булуы әллә кайдан күренеп тора. Монда Африка һәм Азия илләреннән килгән төрле раса яшьләре дә күп укый. Илчелекләр, сәүдә вәкилләре, банклар үзләренә игътибарны тартып тора.


Измир

Измир – Төркиянең иң борынгы шәһәрләреннән берсе. Аңа безнең эрага кадәр унынчы гасырда нигез салынган.

Измир шәһәре мәгариф һәм мәдәният үзәге буларак та атаклы. Музей ныгытма Кәдификала (Хәтфәкала) тау башында урнашкан. Ул – урта гасырлар һәйкәле. Аннан бөтен Измир уч төбендәге шикелле күренә. Йөздән артык мәчет арасында Хисар, Шадырван иң борынгылар.

Измир шәһәрендә спортның баскетбол, көрәш төрләре киң таралган.

Ислам институты, Икътисад һәм сәүдә академиясе, тугызынчы сентябрь һәм Эгей университетлары аеруча дан тота.



Истанбул

Истанбул шәһәре диңгезләр ярында урнашкан. Ярдан ерак түгел Мәрмәрә диңгезе эчендәге утрауда су анасы сарае кебек йорт бар. Әлеге сарай-йорт хакында матур риваять яши. «Кыз манарасы» дип йөртәләр аны.

Истанбул Мәрмәрә диңгезе, Кыр диңгез бугазы һәм Алтын мөгез култыгы белән чикләнгән түбәдә римлылар тарафыннан салына башлый. Римлыларның юлбашчы исеме белән Византия дип атала. Рим императоры аны башкаласы итә. Икенче исеме Константинополь була.

1433 елда төрек солтаны II нче Мәхмәт Константинопольне яулап ала. Аны үз дәүләтенең башкаласы итә.

Иң атаклы мәчет Айя Суфия исеме белән йөртелә. Сөләймания мәчете матурлыгы ягыннан Айя-Суфияне дә узып китә.

Хәзер музейга әйләндерелгән Тупкапы сарае да ерак заманнар истәлеге. Анда 1839 елга чаклы егерме биш төрек солтаны яшәгән. Шәһәр ике кыйтгада урнашкан. Босфор бугазы аша асма күперләр салынган Истанбул Кара диңгез бугазына һәм Мәрмәрә диңгезенә таба да җәелә.

Истанбул ундүрт тау түбәсенә урнашкан.

Истанбулдагы университетлар атаклы уку йортларыннан санала. Аларның берсе генә «Истанбул университеты» дигән исемне йөртә. Калганнары Йолдыз, Мәрмәрә, Бугазэче, Мигъмар Синан, Көч, Сабанчы исемнәрендә.









Төркия мәмләкәте Азия һәм Аурупа кыйтгаларында урнашкан. Ул таулы ил, аның көнчыгышындагы биек-биек түбәләрдә мәңгелек кар ята. Елгалар барысы да диярлек таулардан башлана.

Тауларда ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, Кара диңгез буйларында цитрус җимешләре, чәй һәм тәмәке үсә. Төркиядә сәлви (кипарис), көмешсу чыршы, чинар, магнолия, зәйтүн, чикләвек, йөзем (виноград), армут (груша), анар (гранат), шәфталу (персик) бик күп.

Төрекләр дин ягыннан мөселман саналалар. Төрек теле татар теленә бик якын.





Төркиянең иң зур шәһәрләреннән Истанбул, Анкара, Измир, Адана санала. Истанбулда – 12 миллион, Анкарада 7 миллион халык яши.







Урыс патшасы Петр I гомере буе төрекләрне, Истанбулны басып алу хакында хыялланган. Үзенең кулыннан бу кабахәтлек килеп чыкмагач, васыятендә дә язып калдырган. Менә аның васыятеннән берничә җөмлә: «Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Аурупа илләренең хәзинәсе булган Истанбулга күчерү шарт. Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак».




Мостафа Кәмал (Ата Төрек)

М.Кәмал Солоники шәһәрендә туа. Истанбулда Баш штаб хәрби академиясен тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында хәрби эшлекле булып таныла.

Солтан чит илләр сүзен тыңлый башлагач, ул иптәшләре белән Анкарага китә. Үз тирәсенә ватандар көчләрне туплый башлый. Яңа Милли Мәҗлес (парламент) сайлый. Бәйсез хөкүмәт оештыра. Бу чакта генерал Мостафа Кәмалның нибары 120 солдаты була. Йөз меңнәрчә сугышчысы булган дошманны М.Кәмал гаскәре диңгезгә себереп түгә.

1923 елда Төркия Республика дип игълан ителә. Солтанлык бетерелә. Дәүләтнең яңа үсеш дәвере башлана.



Урыс һәм Аурупа тарихчылары Төркия тарихы хакында ялган китаплар язды. Төрек халкы тарихын бозып күрсәтте. Төрекләр бу илгә безнең эрага кадәр биш мең еллар элек килеп урнаша. Борынгы шумер, хури (хуррей), һәтит (хетт), аккад халыклары составында төрек кабиләләре күп була.

Татар белән төрек бер ата-бабадан яралган. Уртак гореф-гадәтләребез, халык авыз иҗатыбыз бик якын, уртак энҗеләр бихисап.

Татарлар да, төрекләр дә берүк вакытта Ислам дине кабул итәләр.



Зыя КҮГАЛЫП

Хәерле иртә!

Җиргә шәфәкъ түгелгән,
Торам кошлардан алда
Һәм кабатлыйм күңелдән:
Лә илаһи иллалла!
Күктә йолдызлар сүнәр,
Ал гөлләр көлемсерәр,
Былбыллар башын ияр:
Лә илаһи иллалла!
Талгын диңгез уяныр,
Зәңгәр төскә буяныр.
Ул да Алланы таныр:
Лә илаһи иллалла!

Төрекчәдән Ркаил ЗӘЙДУЛЛА
тәрҗемә кылды.





Зыя КҮГАЛЫП

Бөек Болан эзеннән

Йөгереп урамга чыктым,
Туп уйнадым, ачыктым.
Кинәт дөнья болганды,
Күрдем мин бер Боланны.
Киек качты урманга,
Тотам, диеп торганда.
Бер ак Лачынга мендем.
Тиз барам, дип сөендем.
Ай киттем дә ел киттем,
Каф тауларына җиттем.
Лачын ташлады күлгә,
Күлдән чыктым бер чүлгә.
Киек эзенә төштем,
Кулны сузып күрештем.
Киек, күргәч тә мине,
Нигәдер бик сөенде.
Бирде миңа бер алма:
«Шуның артыннан калма.
Таулардан бар, кырдан кит,
Алтын сарайга ук җит.
Сине көтәдер әле
Анда дөнья гүзәле».
Көн туды да кич булды,
Чак эзләп таптым юлны.
Әрләсәләр әрләрләр,
Ак сакаллы кәрләләр,
Тукталмый алга бардым,
Таулар аша юл ярдым.
Диюләр дә сүз катты,
Җеннәр мәтәлчек атты,
Кисекбаш та күренде,
Чәчләренә сөртенде.
Фәрештәләр килгәннәр,
Такыялар кигәннәр.
Диюнең кулы бәйле,
Карана әйле-шәйле.
Кылычымны чыгардым,
Пәриләрне коткардым.
Канатларын ачтылар,
Сәлам биреп качтылар.
Көн киттем дә ай киттем,
Алтын сарайга җиттем.
Бер капкасы ачылды,
Икенчесе ябылды.
Бер төрттем, ике төрттем,
Ишегалдына үттем.
Анда – ат, алдында – ит,
Печәндә ята ач эт.
Печәнне атка бирдем,
Итне эткә китердем.
Бүлмәгә килеп кердем,
Анда бер шаһны күрдем.
Балкый гүя мең кояш –
Бөтен җирдә асылташ.
Мин шаһның башын кистем,
Тәгәрәп китте мескен.
Дидем: «Гыйфрит, әйт әле,
Кайда дөнья гүзәле?»
Кисекбаш әйтте миңа:
«Әйләнеп бак артыңа!»
Борылдым, анда кыргыз
Киеме кигән бер кыз –
Пешкән җимеш, кил дә өз!
Карадым – калдым телсез.
«Төрк бәе! – диде ул. –
Читен булмадымы юл?
Җирнең дәү диюенә
Каршы чыктың син генә.
Кыя телдең, тау ярдың,
Килдең, мине коткардың».
Нечкәрде күңел, эчтән
Еладым сөенечтән.
«Фәрештәсе Туранның!
Син йокыдан уяндың,
Инде безнең белән кал –
Мәңгелек бөек хыял!
Йөз миллион төрк анда
Сине көтә Туранда.
Әйдә, – дидем, – ашыгыйк,
Хәзер үк юлга чыгыйк.
Сүнгән учак җанлансын,
Юксыл илем данлансын».
Киттек, җәяү атладык,
Ат сыртына атландык.
Юлыбыз өйгә таба,
Килдек тимер капкага.
«Ачыл!» – дидем, ачылды,
Фәрештә дога кылды.
Баш иде үзән, үре –
Ияртте Соры Бүре.
Каф тавы аша үттек,
Төрк иленә җиттек.

Төрекчәдән Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемә кылды.





Оста

Төрек халык әкияте

Борын-борын заманда бер байның бик матур, бик чибәр кызы булган ди. Кешеләр аның матурлыгына сокланып, күзләрен алалмый торганнар. Буеның зифалыгын – кипарис, ә чибәрлеген гөлләр патшасы роза белән тиңләгәннәр. Шуңа күрә исемне дә Гөлчәчәк дип кушканнар аңа. Бик кадерле, бик иркә тормышта яшәгән кыз, хәтта аны өрмәгән җиргә дә утыртмаганнар.

Кызганыч, бу бәхет озакка бармаган, Гөлчәчәкнең әти-әнисе, бер-бер артлы авырып, якты дөнья белән хушлашкан. Кыз көн-төн яшь түккән, Алладан ялварып, сабырлык сораган. Вакыт уза торган, йөрәк яралары әкренләп төзәлгән.

Көннәрдән бер көнне кызның да йортына бәхет ишек шакыган. Тирә-юньдә үзенең матурлыгы һәм пәһлевандай көче белән дан казанган егеткә кияүгә чыккан ул. Алар бик матур яши башлаганнар. Егет иртәдән кичкә кадәр эшләгән, шуңа күрә өй эшләренең барысы да Гөлчәчәкнең җилкәсенә төшкән. Ләкин иркә тормышта яшәгән кыз берни дә эшли белми икән. Әкренләп йортның яме тәмам киткән, морҗасы корымланып, каралып калган. Бик сабыр ирнең дә түземлеге бетә башлаган, кайгысы йөзенә чыгып, кашлары ачудан җимерелгән.

кyллар



Гөлчәчәк тагын Аллага ялварган, ярдәм сораган. Догаларын укый торгач, кинәт тылсымчы хатын пәйда булган:

– Син ник шулкадәр кайгырасың, туган көнеңдә үк Алла синең кулларыңны теләсә кайсы эшне эшли алу сәләте белән яратты. Аларны дога укып уятырга гына кирәк. Тик бер шартым бар, эшли башлаган кулларны эшсез тотарга ярамый, юкса алар үз тылсымын югалтыр, – дигән.

Тылсымчы ничек кинәт пәйда булса, нәкъ шулай юкка да чыккан. Кыз шаккатып ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап калган. Шундый уйлар белән баш очына яулыгын бәйләп, эшләп карарга булган.

Тик ни хикмәт, могҗиза чыннан да тормышка ашкан. Куркып кына эшкә тотынган Гөлчәчәк ялт итеп өйне җыештырган, иренә тәмле ризыклар әзерләгән. Кич белән өенә кайткан ире зур үзгәрешләрне күреп:

– Кадерлем, Гөлчәчәгем, менә безнең йортыбызга да ямь керде. Синең кулларың аруны белмәсен. Гел шулай бәхетле яшик, – дигән.

Шул көннән башлап алар бик бәхетле яшәгәннәр, йөзләре көләч, күңелләре тыныч булган.

Нәфис ИСХАКОВ тәрҗемә кылды.

Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА



Төркиядә бер





Узган елның алтын көз аенда бик зур әдәбият бәйрәме үтте. Ефрат (төрекчә Фырат) елгасы буенда урнашкан Елазык шәһәрендә узды әлеге тантана. «Хазар әдипләре мәҗлесе» дип атала ул. Елазык шәһәре янында «Хазар күле» дигән күл бар. Исем әнә шуннан килә.

Ошбу бәйрәм кысаларында дөньяга танылган язучы Чыңгыз Айтматов көннәре дә булды. Чыңгыз ага бу чарада үзе дә катнашты.

Ч.Айтматовның әтисе кыргыз, әнисе Нәгыймә апа татар хатыны булган. Шуңа күрә әдип татарча әйбәт сөйләшә. Күрәсең, туган тел балага ана сөте белән керә, дип юкка гына әйтмиләрдер.

Зиннур ХӨСНИЯР.



















Төрек солтаны Мәхмәтнең гүзәл кызы турында риваять

Чегән күрәзәчесе солтанга: «Кызыңны елан чагып үтерәчәк», – дигән. Солтан моңа бик кайгырган. Диңгез уртасына әнә шул манара-сарайны салдырып, анда кызын яшергән. Солтан кызының матурлыгы хакындагы хәбәр дөнья буйлап таралган. Бу турыда Иран шаһзадәсе дә ишеткән. Мәхәббәт билгесе итеп шаһзадә солтан кызына бик зур бәйләм гүзәл чәчәкләр җибәрә. Чәчәк бәйләме кызга бик ошый, ул аны күкрәгенә кыса. Чәчәк бәйләме арасында агулы елан була, ул кызны чага. Бу турыдагы хәбәр шундук шаһзадәгә дә барып җитә. Ул тиз генә диңгезгә сикерә һәм кыз янына йөзеп килеп җитә. Шаһзадә җәрәхәттәге агуны авызы белән суыра, кыз терелә. Шуннан соң солтан Мәхмәт бу батыр егеткә гүзәл кызын кияүгә бирә.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Мин өч телдә сөйләшәм

Русча-татарча-төрекчә сүзлек

СЧЕТ	ИСӘП	SAYILAR
Сколько?	Ничә? Күпме?	Kaç?
1 – один	бер	bir
2 – два	ике	iki
3 – три	өч	üç
4 – четыре	дүрт	dört
5 – пять	биш	beş
6 – шесть	алты	altı
7 – семь	җиде	yedi
8 – восемь	сигез	sekiz
9 – девять	тугыз	dokuz
10 – десять	ун	on

ЦВЕТА	ТӨСЛӘР	RENKLER
белый	ак	beyaz, ak
черный	кара	siyah, kara
голубой	зәңгәр	lacivert
синий	күк	mavi
зеленый	яшел	yeşil
желтый	сары	sarı
красный	кызыл	kırmızı, kızıl
серебряный	көмеш	gümüş
серый	соры	gri, boz
фиолетовый	миләүшә	mor
светлый	аксыл	açık renk
тёмный	караңгы	koyu renk
яркий	яп-якты, ачык	parlak
светло-синий	аксыл-зәңгәр	açık mavi
ярко-желтый	бик сары	koyu sarı

СВОЙСТВА	СЫЙФАТЛАР	SIFATLAR
большой	зур	büyük
великий	бөек	yüce (ulu)
высокий	биек, югары	yüksek, üstün
горячий	эссе, кайнар	sıcak, kaynar
грязный	пычрак	kirli, pis
густой	куе	koyu, yoğun
дешевый	арзан	ucuz
жесткий	каты	sert, katı
живой	тере	canlı, diri
жидкий	сыек	sıvık, açık
жирный	симез, майлы	yağlı
кислый	әче	ekşi
короткий	кыска	kısa
красивый	матур, чибәр	güzel
круглый	түгәрәк	yuvarlak
легкий	җиңел	hafif
маленький	кечкенә	küçük
молодой	яшь	genç
мокрый	юеш, сулы	yas, sulu
мягкий	йомшак	yumuşak
низкий	түбән, тәбәнәк	aşağı, alçak
новый	яңа	yeni
острый	үткен	keskin, sivri
плохой	начар	kötü
полный	тулы	dolu
пустой	буш	boş
свежий	яңа, саф	taze
сладкий	баллы, татлы	tatlı

Төркия үзенең туңдырмасы (мороженое) белән атаклы. Төрекчә ул «Кахраманмараж» дип атала. «Мар» елан дигән сүз. Византияләрдә – «марсаки», гарәптә – «мәрәж». Кахраман...мараж. «Мараж» сүзе урыс телендә «морож»га әйләнмәдеме икән? «Морож» – «Мороженое»!..



Инглизчә дә яхшы бел




head – баш.

eye – күз.

cheek – бит.

chin – ияк.

neck – муен.



hair – чәчләр.

lashes – керфекләр.

ear – колак.

nose – борын.

lips – иреннәр.

This is a doll. Бу – курчак.



This is her right hand.
Бу аның уң кулы.

This is her left hand.
Бу аның сул кулы.

This is her fingers.
Бу аның бармаклары.

?

?

She has got two hands. Аның ике кулы бар.
She has got two legs. Аның ике аягы бар.
She has got ten fingers. Аның ун бармагы бар.

БИРЕМ: сорау билгеләре урынына дөрес җаваплар биреп кара.

ЗИЛӘ рәсемнәре

Кадерле дускай!
Сиңа Яңа елда яңа бүләк!

Бу елдан синең өеңә «Сыбызгы» да килеп торачак. Әлбәттә, «Салават күпере»нә ияреп. «Сыбызгы» «Салават күпере» журналына язылган баланың кулына сызгыртып килеп керәчәк. Өч айга бер мәртәбә.

Аны «Салават күпере» белән бутамагыз. «Сыбызгы» – аның энесе. «Сыбызгы»га аерым язылып торасы юк!


Дускай! Сиңа тагын бер күчтәнәч!

«Сыбызгы» берьюлы өч телдә чыга. Татар, инглиз һәм рус телләрендә. Ходай теләсә, төрек телен дә өйрәнә алырсың әле...


Ә татар телен бик яхшы өйрәнсәң, башка чит телләрне дә өйрәнә алырсың, иншалла!

Дәү үскәч, зур кеше булырсың, Алла боерса! Космонавтлар кебек галәмгә очарсың! Белеп тор: башка планеталарда бары тик татар телендә генә сөйләшәләр. Чөнки төрки-татар теле бик борынгы тел!

Сәлам белән
«Сыбызгы».







Салават күпере

1(214) — 2008

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛЬ: ОАО «ТАТМЕДИА».
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер* үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-Пресс» ААҖ.

Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 17.1.2008 ел.

Басарга кул куелды 17.1.2008 ел.

Кәгазь форматы 60х90 1/8.

Гарнитура – Прагматика.

Офсет ысулы белән басыла.

Тираж 11411 данә. Заказ Т-4.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953




«Туган авылым» балалар рестораны – бәхетле балачак иле!

Балалар өчен махсус ризыклар,
туган көн кичәләре.

Кадерле балагызга истәлекле бәйрәм бүләк итәсегез килсә – рәхим итегез!





Безнең адрес:
Казан шәһәре,
Луковский урамы, 14/56,
тел.: 533-80-91.

